**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.01.2015 № 2

Нурлат муниципаль районы территориясендә Һач ману бәйрәме бәйле массакүләм чаралар вакытында су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү турында

Нурлат муниципаль районы халкы иминлеген тәэмин итү, Һач ману православие бәйрәмен бәйрәм иткәндә су объектларында бәхетсезлек очракларын булдырмау максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районының Биляр-Озеро, Иске Чаллы һәм Мамык авылында махсус җиһазландырылган буаларны Һач ману бәйрәме төнендә су коену урыннары итеп билгеләргә.

2. Нурлат шәһәре (Сафиуллин Н.С.) һәм авыл җирлекләре башкарма комитет җитәкчеләренә Һач ману бәйрәмендә коену белән бәйле массакүләм чаралар уздырганда җиһазландырылмаган су объектларында коенуны тыю һәм кешеләрнең боз өслегенә чыгарга ярамавын кисәтергә киңәш итәргә.

3. Нурлат шәһәренең полиция начальнигы (Нургатин Х. Ш.) һәм 125 нче бүлек (Курамшина И. И.) җитәкчесенә массакүләм чаралар уздыру урыннарында хезмәткәрләрнең кизү торуын оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Роспотребнадзор Идарәсенең Нурлат муниципаль районындагы территориаль бүлеге начальнигына һәм Нурлат шәһәренә (Әндәрова Д. К.) коену урыннарында суның лаборатория анализын алырга тәкъдим итәргә.

5. Нурлат үзәк хастаханәсе ДАССОның баш табибына (Йосыпов М. Р.) массакүләм чаралар уздыру урыннарында ашыгыч ярдәм бригадасының кизү торуын оештырырга киңәш итәргә.

Җитәкче А.К. Габдуллин